| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

**«26» август 2022г.** с. Тюлячи № 157

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең бәяләвенә керә торган кирәкле белешмәләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 21 июлендәге 9760/22 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең бәяләвенә керә торган кирәкле белешмәләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 08 2022 № 157
карарына кушымта

**Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең бәяләвенә керә торган кирәкле белешмәләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы

Әлеге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең бәяләвенә керә торган кирәкле белешмәләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары,«Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына «Контроль» модуленең эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнелгән һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) бәяләвенә керә торган түбәндәге кирәкле белешмәләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели:

2015 елдан башлап хисап елы тәмамланганчы танылган сәләтләре һәм талантлары ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өчен, процент;

хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме алган һәм күренекле сәләтләрен күрсәткән 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, процентлар.

Теләче муниципаль районында декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау өчен «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) җаваплы.

1.2. Белешмә мәгълүматы

Әлеге регламент максатлары өчен муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм

үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткеченең бәяләвенә кирә торган кирәкле белешмәләрне исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла, Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә, алар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән.

## 2. Исәп-хисап стандарты, җыю тәртибе һәм белешмәләр бирү

Декомпозицияләнгән күрсәткечләрне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләрнең гомуми саны, кеше;

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, 2015 елдан башлап Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән олимпиадаларда һәм башка конкурс чараларында җиңүче булган һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында мәкаләләр авторлары булып торучы балалар, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмалар саны (Web of Science, Scopus h.б.), кеше (алга таба - 2015 елдан башлап сәләтләре һәм талантлары ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны);

хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме күрсәткән һәм дәүләт ярдәмен алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре югарыда күрсәтелгән ярдәмче күрсәткечләр буенча хисап чорында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра:

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балаларның һәм яшьләрнең гомуми саны буенча - «Ачык Татарстан» системасы мәгълүматлары нигезендә;

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны буенча, аларда 2015 елдан алып талантлар ачыкланган - әлеге муниципаль районда (шәһәр округында) урнашкан гомуми белем бирү оешмаларыннан балалар турында мәгълүматлар базасын җыю гамәлгә ашырыла.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре электрон рәвештә мәгълүматлар җыю формасын җибәрә, анда мәгариф оешмасы вәкилләре укучыларның казанышлары турында белешмәләр кертәләр:

1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән конкурс чараларында призлы урыннар;

2. интеллектуаль эшчәнлекнең теркәлгән нәтиҗәләре;

3. мәкаләләрнең халыкара яисә бөтенроссия фәнни басмаларында, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмаларда (Web of Science, Scopus) бастырылуы.

Танылган сәләтләр күрсәткән Балалар турында мәгълүматлар базасы бөтен муниципаль район (шәһәр округында) җыелма электрон формада, яшь кешеләрне һәм аларның казанышларын ел саен исәпкә алу өчен, шулай ук алар алган ярдәм чараларын алга таба теркәү өчен саклана.

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны буенча, үзләренең сәләтләрен таныткан һәм хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме алган балалар һәм яшьләр саны буенча - мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре узган елның 11нче сыйныф укучыларында танылган сәләтләрен күрсәткән балалар турында мәгълүматлар базасына кертелгән дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат сорату юлы белән мәгълүматлар җыя. Мониторингка тиешле дәүләт ярдәме чаралары ел саен, 2023 елдан башлап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре муниципаль район (шәһәр округы) буенча җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан ачык талантлар университеты 2.0» АКБО адресына mon.sbor@tatar.ru һәм info@utalents.ru электрон почтасы адресына мәгълүмат копиясе белән Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән җибәрә. 2023 елдан сәләтле балалар турында мәгълүматлар базасын җыю АКБО «Казан талантлар университеты 2.0» порталы аша гамәлгә ашырылачак.

## 3. Мәгълүматларның составы, бирелү срогы һәм китереп торучылары

3.1. Хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме күрсәткән һәм дәүләт ярдәмен алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше

3.2.

| № т/б | Оешманың атамасы | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, алар күренекле сәләтләрен күрсәтеп, төрле формаларда дәүләт ярдәме алган хисап елында |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

3.3. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) мәкаләләр авторлары булып торучы, фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмасында булган, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмада (Web of Science, Scopus h.б.) җиңүче яисә призер булган 7 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны

| № т/б | Оешманың атамасы | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | 2015 елдан башлап сәләтләре һәм талантлары ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны хисап елында |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |